| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2021 ел Лениногорск ш. № 366

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2009 елның 17 сентябрендәге 1318 карары белән расланган авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2009 елның 17 сентябрендәге 1318 карары белән расланган авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5. пунктында 6 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр булган документлар күчермәсе яисә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;»;

2.6. пунктта (хакимият органнары карамагында булган мәгълүматлар):

«Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта)» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүмат-Россия Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә аллыштырырга;

3.4.1 пунктта (ведомствоара запрослар юнәлеше):

«Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта)» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр» сүзләренә алыштырырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72